Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданка Н.Е. Мешкова шикаятенә бәйле рәвештә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 2 нче номерлы кушымтаның, 3 нче номерлы кушымтаның I өлешендәге 2 һәм 9 пунктларының, исеменең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2021 елның 2 марты

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Ф.С. Мусин, Э.М. Мостафина, Г.Л. Удачина, М.М. Хәйруллин составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып, ачык суд утырышында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 2 нче номерлы кушымтаның,

3 нче номерлы кушымтаның I өлешендәге 2 һәм 9 пунктларының, исеменең конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданка Н.Е. Мешкова шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив хокукый нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Ф.Р. Волкова мәгълүматын, яклар — гражданка Н.Е. Мешкова, аның вәкилләре — В.Б. Летавин, Ә.Т. Габдрахманова, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсенең юридик бүлеге башлыгы Р.Н. Сафин, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле үтенечнамәсе буенча суд утырышына чакырылган — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсенең муниципаль торак фондын исәпкә алу һәм бүлү бүлеге башлыгы Е.Н. Смагина аңлатмаларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Н.Е. Мешкова Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба шулай ук — Административ регламент) 2 нче номерлы кушымта, 3 нче номерлы кушымтаның I өлешендәге 2 һәм 12 пунктлары, исеме белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Административ регламентка 2 нче номерлы кушымта белән Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алуны гамәлгә ашыра торган Казан шәһәре Башкарма комитетының тиешле районы администрациясендә (алга таба шулай ук — Администрация) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык турында гариза формасы билгеләнгән.

Административ регламентка 3 нче номерлы кушымта «Муниципаль хезмәт, шулай ук хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге» дип атала.

Административ регламентка 3 нче номерлы кушымтаның I өлешендәге 2 һәм 12 пунктлары (мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән вакытта гамәлдә булган редакциясендә) гражданнарны социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен түбәндәге документлар кирәклеген күздә тота: гариза бирүченең, аның гаилә әгъзаларының һәм алар белән бергә теркәлгән барлык гражданнарның, яисә аларның законлы вәкилләренең әлеге регламентның 2 нче номерлы кушымтасындагы форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы турында гариза, шулай ук, әлеге затларның шәхси мәгълүматларын исәпкә ала торган органга тапшырганда, гариза бирүченең алар исеменнән эш итү вәкаләте (2 пункт); гариза бирүченең, аның гаилә әгъзаларының һәм алар белән бергә теркәлгән барлык гражданнарның даими яшәү урыны буенча милек хокукында торак урыннары булу (булмау) турында техник инвентаризацияләү органыннан белешмәләр; 1991 елның 11 июленнән 2000 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасыннан читтә теркәлгән булса — теркәлү урыны буенча муниципаль берәмлекнең техник инвентаризацияләү органыннан өземтә (12 пункт).

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка Н.Е. Мешкова Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2012 елның 29 ноябрендәге 987н номерлы боерыгы белән расланган гражданнарның бер фатирда бергә яшәүләре мөмкин булмаган хроник авыруларның авыр формалары исемлегенә кертелгән авыру буенча II группа инвалид һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәскәү районы администрациясе башлыгының 2009 елның 27 маендагы 319-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә чираттан тыш торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәптә тора. Уңайлыклары булган торак урыны алу, торак урыны алуга торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) бирүгә мохтаҗ буларак исәпкә кую максаты белән, шулай ук «Аз керемлеләр» категориясе буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куюны сорап, мөрәҗәгать итүче берничә тапкыр Казан шәһәре Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясенә мөрәҗәгать иткән, әмма аңа, аерым алганда, документларның тулы пакеты, шул исәптән барлык гаилә әгъзаларының шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык турында гариза, шулай ук гаилә әгъзасының милек хокукында торак урыннары булу (булмау) турында техник инвентаризацияләү органыннан белешмәләр тапшырылмау сәбәпле, баш тартылган. Аның гомуми юрисдикция судларына дәгъва белән мөрәҗәгать итүләре канәгатьләндерелмичә калган.

Гражданка Н.Е. Мешкова Административ регламентка 2 нче номерлы кушымта, 3 нче номерлы кушымтаның I өлешендәге 2 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуны аларда гражданнарны Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүченең, аның гаилә әгъзаларының һәм алар белән бергә теркәлгән барлык гражданнарның, яисә аларның законлы вәкилләренең тиешле

форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы турында гариза бирү зарурлыгы каралуда күрә.

Мөрәҗәгать итүче уйлаганча, «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренең мәгънәсе буенча муниципаль хезмәтләр алу өчен мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүченең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык бирүе мәҗбүри шарт түгел.

Шулай ук, гражданка Н.Е. Мешкова фикеренчә, Административ регламентка 3 нче номерлы кушымтаның I өлешендәге 12 пунктында каралган гариза бирүченең, аның гаилә әгъзаларының һәм алар белән бергә теркәлгән барлык гражданнарның даими яшәү урыны буенча милек хокукында торак урыннары булу (булмау) турында техник инвентаризацияләү органыннан белешмәләр; 1991 елның 11 июленнән 2000 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасыннан читтә теркәлгән булса — теркәлү урыны буенча муниципаль берәмлекнең техник инвентаризацияләү органыннан өземтә тапшыру зарурлыгы аның торакка конституциячел хокукларын чикләү булып тора, ә «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешенең «ж» пунктчасы нигезендә, гражданнарны торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен гаилә әгъзаларының даими яшәү урыны буенча милек хокукындагы торак урыннарының булуы яки булмавы турында дәүләт кадастр исәбенә алуны, хокукларны дәүләт теркәвенә алуны, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып баруны һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булган мәгълүматларны бирүне гамәлгә ашыручы органнан белешмәләр кирәк, ул мөрәҗәгать итүче гаиләсенең хокуктан файдалануга сәләтле һәр әгъзасыннан гариза бирелгән елга кадәрге биш ел өчен тапшырыла. Шул ук вакытта күрсәтелгән статьяның 4.1 өлешенең икенче абзацы нигезендә әлеге документ граждан тарафыннан үз инициативасы белән

тапшырылырга мөмкин, ә тапшырылмаган очракта ул вәкаләтле орган тарафыннан аның карамагында шундый мәгълүматлар булган тиешле органнан соратып алына.

Гражданка Н.Е. Мешкова Административ регламентка 3 нче номерлы кушымта исеменең аның эчтәлеге белән туры килмәвен билгеләп үтә. Шулай, исеменнән кушымтада күрсәтелгән исемлек буенча документларны бары тик мөрәҗәгать итүче үзе генә тапшырырга тиешлеге аңлашыла, шул ук вакытта әлеге исемлектән кайбер документларга карата турыдан-туры аның эчтәлеге мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны тапшыру мөмкинлеген генә күз алдында тота.

Бәян ителгәннәр нигезендә мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституция судыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 2 нче номерлы кушымтаны, 3 нче номерлы кушымтаның I өлешендәге 2 һәм 12 пунктларын, исемен Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 24 (икенче өлеш), 28 (беренче өлеш), 32, 54 (беренче өлеш), 55 статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре — иң зур хәзинә; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау — Татарстан Республикасының бурычы; Татарстан Республикасы — сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт; дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, оешмалар, учреждениеләр, вазыйфаи затлар һәм гражданнар Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә тиеш; закон һәм суд каршында һәркем тигез; шәхеснең абруе дәүләт тарафыннан саклана; аны төшерү өчен бернәрсә дә нигез була алмый; һәркемгә яше буенча, авырган, гарипләнгән, туендыручысын югалткан очракта, балаларны тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә; һәркем

торакка хокуклы; беркем дә торагыннан нигезсез рәвештә мәхрүм итеlә алмый; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар.

Гражданка Н.Е. Мешкованың шикаяте Татарстан Республикасы Конституция судының 2020 елның 23 июнендәге 15-О номерлы билгеләмәсе белән карауга алынган иде.

Эшне суд утырышында карый башлаганда Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 29 сентябрендәге 2738 номерлы карары белән Административ регламентка, шул исәптән мөрәҗәгать итүче шикаять белдерә торган 3 нче номерлы кушымтага үзгәрешләр кертелгән. Шулай итеп, кертелгән үзгәрешләр нигезендә Административ регламентка 3 нче номерлы кушымтаның 1 өлешендәге 12 пункты Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынына мохтаҗ буларак исәпкә кую өчен мөрәҗәгать итүчегә гариза бирүченең, аның гаилә әгъзаларының һәм 2000 елның 1 гыйнварына кадәр алар белән бергә теркәлгән барлык гражданнарның даими яшәү урыны буенча милек хокукында торак урыннары булу (булмау) турында техник инвентаризацияләү органыннан белешмәләр тапшыру зарурлыгын күздә тоткан 9 пункт булган.

Кертелгән үзгәрешләр белән бәйле рәвештә гражданка Н.Е. Мешкова Татарстан Республикасы Конституция судына Административ регламентка 3 нче номерлы кушымтаның I өлешендәге 9 пунктының конституциячеллегенә дәгъва белдерелә дип ачыклаган гариза белән мөрәҗәгать итте.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар

кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, әлеге эш буенча түбәндәгеләр Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора:

— Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 2 нче номерлы кушымтаның, 3 нче номерлы кушымтаның I өлешендәге 2 пунктының үзара бәйле нигезләмәләре, алар Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчегә гариза бирүченең, аның гаилә әгъзаларының һәм алар белән бергә теркәлгән барлык гражданнарның, яисә аларның законлы вәкилләренең тиешле форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы турында гариза бирү бурычын йөкләгән дәрәҗәдә;

— Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 3 нче номерлы кушымта исеме, аның сүзгә-сүз мәгънәсеннән күренгәнчә, гражданнарны Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле барлык документларны тапшыру бурычы мөрәҗәгать итүчегә йөкләнгән дәрәҗәдә;

— Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 3 нче номерлы кушымтаның I өлешендәге 9 пункты, анда Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчегә гариза бирүченең, аның гаилә әгъзаларының һәм 2000 елның 1 гыйнварына кадәр алар белән бергә теркәлгән барлык гражданнарның даими яшәү урыны буенча милек хокукында торак урыннары булу (булмау) турында техник инвентаризацияләү органыннан белешмәләр тапшыру бурычын йөкләгән дәрәҗәдә.

2. Нигезләмәләренә карата гражданка Н.Е. Мешкова шикаять белдерә торган Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты вәкаләтләренә кагылышлы мәсьәлә элегрәк Татарстан Республикасы Конституция судының тикшерү предметы булган иде, ул, күрсәтелгән норматив хокукый актны кабул итеп, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты үзенә федераль һәм республика законнары нигезендә бирелгән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 116 (беренче өлеш) һәм 118 (беренче өлеш) статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә таянган вәкаләтне дөрес гамәлгә ашырган, дигән нәтиҗәгә килде, алар нигезендә җирле үзидарә, закон нигезендә һәм үзенә җаваплылык алып, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне халыкның мөстәкыйль хәл итүен, муниципаль милек биләүне, аннан файдалануны һәм аның белән эш итүне тәэмин итә; җирле үзидарә органнары муниципаль милеккә мөстәкыйль идарә итәләр, җирле бюджетны төзиләр, раслыйлар һәм үтиләр, җирле салымнар һәм җыемнар билгелиләр, җәмәгать тәртибен саклауны гамәлгә ашыралар, шулай ук

җирле әһәмияткә ия бүтән мәсьәләләрне хәл итәләр (2020 елның 16 июнендәге 91-П номерлы карар). Татарстан Республикасы Конституция судының күрсәтелгән карары һәм анда чагылдырылган хокукый позицияләр үз көчләрен саклый.

3. Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасын сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт дип игълан итеп (13 статья), һәркем торакка хокуклы; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар (55 статья) дип беркетә. Мәгънәсе буенча охшаш гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясендә билгеләнгән (7 статья, 40 статьяның 1 һәм 2 өлешләре).

Әлеге конституциячел нормалар һәркемнең лаеклы тормыш дәрәҗәсенә хокук элементы буларак торакка хокукны танучы халыкара хокукый нормаларга туры килә (1948 елның 10 декабрендәге Кеше хокуклары гомум декларациясенең 25 статьясы, Икътисадый, социаль һәм мәдәни хокуклар турында 1966 елның 16 декабрендәге халыкара пактның 11 статьясы).

Россия Федерациясе Торак кодексының 2 статьясы нигезендә дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары үз вәкаләтләре чикләрендә гражданнарның торакка хокукын гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин итәләр, шул исәптән бюджет акчаларын һәм законда тыелмаган башка акча чыганакларын гражданнарның торак шартларын яхшырту өчен, шул исәптән торак биналар сатып алу яисә төзү өчен билгеләнгән тәртиптә субсидияләр бирү юлы белән файдаланалар (2 пункт); дәүләт яисә муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре яки торак биналарны наем шартнамәләре буенча гражданнарга билгеләнгән тәртиптә торак биналар бирәләр (3 пункт).

3.1. Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык турында гаризаны гражданнарны Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә

торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен кирәкле документлар исемлегенә керткәнгә күрә, Административ регламентның 2 нче номерлы кушымтасы һәм 3 нче номерлы кушымтасының I өлешендәге 2 пункты нигезләмәләренә гражданка Н.Е. Мешкова тарафыннан дәгъва белдерелә.

Административ регламент үзенең эчтәлеге буенча гариза бирүченең, аның гаилә әгъзаларының һәм алар белән бергә теркәлгән барлык гражданнарның Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алуга хокукын тормышка ашыруга юнәлдерелгән муниципаль хезмәт күрсәтүнең оештыру-процедура механизмын билгели һәм үзенең хокукый табигате буенча гражданның күрсәтелгән хокукын тормышка ашыру өчен кирәкле гамәлләрне тулысынча регламентларга тиеш.

Шикаять белдерелә торган Административ регламентка 2 нче номерлы кушымтада Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алуны гамәлгә ашыра торган Казан шәһәре Башкарма комитетының тиешле районы администрациясендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык турында гариза (алга таба шулай ук — шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык турында гариза) формасы каралган, аның эчтәлегеннән күренгәнчә, шәхси мәгълүматлар субъекты бу мәгълүматларны үзен исәпкә кую һәм үзенең законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү максатыннан Администрация тарафыннан өченче затлардан алуга һәм өченче затларга тапшыруга каршы килми, шулай ук аларны саклауга, эшкәртүгә һәм тапшыруга ризалык бирә.

Гаризаның әлеге формасын Административ регламентка дәгъва белдерелә торган 3 нче номерлы кушымтаның I өлешендәге 2 пункты нигезләмәсе белән үзара бәйләнештә карарга кирәк, анда Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында гариза бирүченең, аның гаилә

әгъзаларының һәм алар белән бергә теркәлгән барлык гражданнарның, яисә аларның законлы вәкилләренең аны тапшыру зарурилыгы беркетелгән.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртү белән бәйле мөнәсәбәтләрне җайга салучы, әлеге мәгълүматларны эшкәртү принципларын, шартларын һәм кагыйдәләрен билгеләүче закон актының нигезе — «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль закон (1 һәм 4 статьялар, 6 статьяның 1 өлеше).

Күрсәтелгән Федераль законның 6 статьясындагы 1 өлеше, 7 статьясы, 9 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләренең мәгънәсе буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртү, шул исәптән аларны тарату һәм бирү, аларны эшкәртүгә шәхси мәгълүматлар субъекты ризалыгы булмаганда, федераль законда каралган очракларда гына рөхсәт ителә. «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законның 6 (2 өлешнең 4 пункты) һәм 10 (2 өлешнең 6 пункты) статьяларының үзара бәйле нигезләмәләреннән күренгәнчә, мондый очракларга, аерым алганда, «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законда каралган муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәү өчен кирәкле шәхси мәгълүматларны эшкәртү, ә шәхси мәгълүматларның махсус категорияләренә карата (мәсәлән, сәламәтлеге турындагы мәгълүматлар) шәхси мәгълүматлар субъекты яки өченче затларның хокукларын билгеләү яки гамәлгә ашыру өчен кирәкле шәхси мәгълүматларны эшкәртү керә.

«Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законның 9 статьясындагы 8 өлеше нигезендә аталган хокукый нигезләр шулай ук шәхси мәгълүматлар субъекты булмаган заттан оператор тарафыннан шәхси мәгълүматларны алу рөхсәт ителгән шартлар булып тора. Шул ук вакытта «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясындагы 3 өлеше, әгәр дә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүче булып тормаучы затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү зарур булса, һәм федераль закон нигезендә андый шәхси мәгълүматлар әлеге затның ризалыгы белән эшкәртелергә мөмкин булган очракта, муниципаль

хезмәтләр алу өчен мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүче өстәмә рәвештә әлеге затның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә әлеге заттан яки аның законлы вәкиленнән ризалык алынуны раслаучы документлар тапшыруын күз алдында тота. Башка сүзләр белән әйткәндә, аталган Федераль законның китерелгән нигезләмәсе шәхси мәгълүматларның махсус категорияләренә караган шәхси мәгълүматларны эшкәртүне рөхсәт итә, ягъни федераль закон чыгаручы шәхси мәгълүматлар субъекты булмаган затның ризалыгыннан башка, аерым алганда, ул аның хокукларын билгеләү яки гамәлгә ашыру өчен кирәк булган очракта, аларны эшкәртү үзенчәлекләрен билгеләгән.

Шулай итеп, югарыда аталган норматив хокукый нигезләмәләрнең системалы анализыннан күренгәнчә, Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәткәндә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык алу таләп ителми. Карала торган муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза формасында (Административ регламентка 1 нче номерлы кушымта) мөрәҗәгать итүче гаиләсенең эшкә сәләтле барлык әгъзаларының имзалары булырга тиешлеге каралуын исәпкә алып, күрсәтелгәннәр мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү уңаеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә дә тулысынча кагыла.

Мондый нәтиҗә Татарстан Республикасы Конституция судының элек формалаштырылган хокукый позициясе белән раслана, аннан күренгәнчә, дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр алу өчен мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүченең аның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы аларны алу өчен мәҗбүри шарт булып тормый; дәүләт хезмәтен алу өчен мөрәҗәгать итеп һәм шуңа кирәкле документларны теркәп, дәүләт хезмәтләрен алучы фактта әлеге хезмәтне күрсәтү өчен кирәкле булган үзенең шәхси мәгълүматларын тапшыруга һәм эшкәртүгә ризалыгын белдерә (2016 елның 27 маендагы 68-П номерлы карар).

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган гражданнарны Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Администрациядә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык турында гариза бирү зарурлыгын күздә тоткан Административ регламентка 2 нче номерлы кушымтаның һәм 3 нче номерлы кушымтаның I өлешендәге 2 пунктының үзара бәйле нигезләмәләре шәхси мәгълүматлар субъектының шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык алу зарурлыгы өлешендә «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль закон белән билгеләнгән хокукый җайга салуны үзгәртәләр, шуңа күрә кирәгеннән артык булалар, шуның белән гражданнарның, шул исәптән гражданка Н.Е. Мешкованың, Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар исәбенә алыну хокукларын чиклиләр һәм аңа аеручa мохтаҗ гражданнарның торакка хокукын тәэмин итү конституциячел әһәмиятле максатларына каршы киләләр һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килмиләр.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм аның нигезләмәләренә таянган Татарстан Республикасы Конституция судының хокукый позицияләрен исәпкә алып, гамәлдәге хокукый җайга салуга әлеге Карардан килеп чыга торган тиешле үзгәрешләрне кертергә кирәк.

3.2. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 2, 6 һәм 12 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләре буенча Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу, муниципаль хезмәт күрсәтү буларак, административ регламент — муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен һәм муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын билгеләүче норматив хокукый акт нигезендә гамәлгә ашырыла.

Аталган Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты административ регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү өчен закон яки бүтән норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның гариза бирүче мөстәкыйль тапшырырга тиешле документлар һәм мәгълүматка һәм гариза бирүче үз теләге белән тапшырырга хокуклы булган (чөнки алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш) документлар исемлегенә бүлеп билгеләүне таләп итә.

Мондый хокукый җайга салуга «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының норматив нигезләмәләре туры килә, андагы 6 статьяның 1 өлешендә гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен кирәкле документлар исемлеге һәм карала торган Административ регламентның, ә нәкъ менә «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегенең 2.5, 2.6 пунктларында гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле һәм Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документлар исемлеге билгеләнгән. Алар Административ регламентка 3 нче номерлы кушымтада җентекләп ачыкланган, ул гариза бирүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тапшырылырга тиешле документларны, шулай ук, алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиешле булганга күрә, ул үз инициативасы буенча тәкъдим итәргә хокуклы документларны күз алдында тота.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белдерә торган кушымтаның исеме «Муниципаль хезмәт, шулай ук хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар

нигезендә кирәкле, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге» буларак билгеләнгән.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге регламентка 3 нче номерлы кушымтаның дәгъва белдерелә торган исеме, анда булган гражданнарны социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен кирәкле документлар исемлеге белән үзара бәйләнештә, үзеннән-үзе аның эчтәлеген һәм муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели торган норматив хокукый акт буларак, тулаем алганда, Административ регламентның эчтәлеген үзгәртми, мөрәҗәгать итүчегә Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле барлык документларны тапшыру бурычын йөкләми, һәм, димәк, гражданнарның, шул исәптән гражданка Н.Е. Мешкованың, конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозучы буларак карала алмый, шуңа күрә Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килми, дигән нәтиҗәгә килә.

Шул ук вакытта Административ регламентка 3 нче номерлы кушымтаның исемен Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килми дип тану Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Административ регламентның Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартының 2.5 һәм 2.6 пунктларының гомуми концепциясеннән чыгучы һәм 3 нче номерлы кушымтаның хокукый эчтәлеген чагылдыручы, аны лингвистик аныклауга юнәлдерелгән өстәмә норматив карарлар кабул итү хокукын юкка чыгармый.

3.3. Административ регламентка 3 нче номерлы кушымтаның 1 өлешендәге шикаять белдерелә торган 9 пункты нигезләмәсе буенча Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу өчен мөрәҗәгать итүчегә гариза бирүченең, аның гаилә әгъзаларының һәм 2000 елның 1 гыйнварына кадәр алар белән бергә теркәлгән барлык гражданнарның даими яшәү урыны буенча милек хокукында

торак урыннары булу (булмау) турында техник инвентаризацияләү органыннан белешмәләрне Администрациягә тапшырырга кирәк.

Россия Федерациясе Конституция Суды үзенең карарларында берничә тапкыр күрсәткәнчә, торакка хокукны гамәлгә ашыру торак законнары актларында беркетелгән аерым таләпләргә бәйле булырга мөмкин (2002 елның 9 апрелендәге 123-О номерлы, 2004 елның 4 мартындагы 80-О номерлы, 2010 елның 15 июлендәге 955-О-О номерлы, 2010 елның 25 ноябрендәге 1543-О-О номерлы һ.б. билгеләмәләр).

Россия Федерациясе Торак кодексының 52 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, граждан тарафыннан, торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу турында гариза белән бергә, исәпкә алуны гамәлгә ашыручы орган тарафыннан ведомствоара мөрәҗәгатьләр буенча алына торган документлардан тыш, аның торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә тору хокукын раслаучы документлар тапшыру кирәклеге шундый таләпләрнең берсе булып тора. Гражданнарны торак исәбенә куюның законлы булуын документаль раслауны күздә тоткан мондый таләп үзеннән-үзе, Россия Федерациясе Конституция Суды билгеләп үткәнчә, гражданнарның нинди дә булса конституциячел хокукларын бозмый (2015 елның 16 июлендәге 1697-О номерлы Билгеләмә).

Мондый документлар исемлеге федераль закон чыгаручы тарафыннан билгеләнмәгән. Россия Федерациясе Торак кодексының 13 статьясындагы 7 пункты нигезендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә гражданнарны торак урыннарга мохтаҗлар буларак җирле үзидарә органы тарафыннан исәпкә алып бару тәртибен билгеләү керә. Моннан тыш, «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктыннан турыдан-туры шуны аңларга кирәк: муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар гариза бирүчедән аларны тапшыру яки андый гамәлләр кылу муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килүче мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актлар белән күздә

тотылмаган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны яки гамәлләр кылуны таләп итәргә хокуклы түгел.

Шуңа бәйле рәвештә республика закон чыгаручысы, Россия Федерациясе Торак кодексында һәм торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарга карата торак законнарының башка норматив хокукый актларында каралган таләпләрдән чыгып, шул ук вакытта кайсы документлар турыдан-туры гражданнар тарафыннан тапшырылырга тиеш һәм кайсылары аларның үз инициативасы буенча тапшырылырга тиеш икәнлеген күз алдында тотып, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законында мондый гражданнарны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә алу өчен кирәкле документлар исемлеген беркеткән.

Аталган Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешенең «а», «б», «в» һәм «г» пунктчаларында (икенче абзацтан тыш), 12 (4 өлештән тыш), 17, 19 һәм 20 статьяларында күрсәтелгән документлар турыдан-туры гражданнар тарафыннан тапшырыла (6 статьяның 4.1 өлешендәге беренче абзацы). Әлеге документлар исемлеге тулы һәм аңа киңәйтелгән аңлатма бирелергә тиеш түгел. Республика законының китерелгән нигезләмәләрен хокукый анализлаудан күренгәнчә, гариза бирүченең, аның гаилә әгъзаларының һәм 2000 елның 1 гыйнварына кадәр алар белән бергә теркәлгән барлык гражданнарның даими яшәү урыны буенча милек хокукында торак урыннары булу (булмау) турында техник инвентаризацияләү органыннан белешмәләр тапшыру бурычы мөрәҗәгать итүчегә йөкләнгән документларга керми.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Конституция суды Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча

гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертмичә генә гариза бирүченең, аның гаилә әгъзаларының һәм 2000 елның 1 гыйнварына кадәр алар белән бергә теркәлгән барлык гражданнарның даими яшәү урыны буенча милек хокукында торак урыннары булу (булмау) турында техник инвентаризацияләү органыннан белешмәләрне тапшыру бурычы мөрәҗәгать итүчегә йөкләнгән документлар исәбенә кертергә хокуклы түгел дигән нәтиҗәгә килә.

Шуның белән бергә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган Административ регламент нигезләмәләре, үзенең сүзгә-сүз эчтәлегеннән чыгып, императив характерга ия, һәм, эш материалларыннан күренгәнчә, югарыда күрсәтелгән документны тапшырмау «Аз керемлеләр» категориясе буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә куюдан баш тартуга китерә.

Шулай итеп, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 3 нче номерлы кушымтаның I өлешендәге шикаять белдерелә торган 9 пункты «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 һәм 4.1 өлешләренең үзара бәйле нигезләмәләренең хокукый җайга салу кысаларыннан чыга һәм мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килүче мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы каралмаган документларны таләп итү рөхсәт ителмәве өлешендә «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законда

билгеләнгән чикләүне боза һәм шуның белән гражданнарның, шул исәптән гражданка Н.Е. Мешкованың, Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар исәбенә алынырга мөмкин булу хокукларын чикли, аңа аеруча мохтаҗ гражданнарны торакка хокук белән тәэмин итүнең конституциячел әһәмиятле максатына каршы килә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм аның нигезләмәләренә таянган Татарстан Республикасы Конституция судының хокукый позицияләрен исәпкә алып, әлеге Карардан килеп чыга торган гамәлдәге хокукый җайга салуга тиешле үзгәрешләр кертергә кирәк.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 84 статьясындагы икенче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы законын яисә башка норматив хокукый актны йә аларның аерым нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тану конституциячел түгел дип танылган яки мөрәҗәгатьтә шундый нигезләмәләре күрсәтелгән актка нигезләнгән башка норматив хокукый актларның нигезләмәләрен юкка чыгаруга сәбәп була. Бу законнарның яисә башка норматив хокукый актларның нигезләмәләрен судлар, башка органнар һәм вазыйфаи затлар кулланa алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73 һәм 84 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Казан

шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 2 нче номерлы кушымтаның, 3 нче номерлы кушымтаның I өлешендәге 2 пунктының үзара бәйле нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танырга.

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 3 нче номерлы кушымта исемен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга, чөнки ул мөрәҗәгать итүчегә гражданнарны Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле барлык документларны тапшыру бурычын йөкләми.

3. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 3 нче номерлы кушымтаның I өлешендәге 9 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танырга.

4. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм аның нигезләмәләренә таянган Татарстан Республикасы Конституция судының хокукый позицияләрен исәпкә алып, гамәлдәге хокукый җайга салуга әлеге Карардан килеп чыга торган тиешле үзгәрешләрне кертергә кирәк.

5. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

6. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 96-П**

**Татарстан Республикасы Конституция суды**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ * КОНСТИТУЦИОННЫЙ СУД РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ИНН 1655039191 * ОГРН 1021602845241